БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_20_» ___09____ 2019 г. № _302_

**Коралны, аның төп өлешләрен, хәрби кирәк - яракларын, коралга патроннарны, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлаткыч җайланмаларны ирекле тапшырган өчен акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы территориясендә корал, хәрби кирәк - яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында" 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (2009 елның 2 апрелендәге 255 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары үзгәрешләр белән) нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Корал, аның төп өлешләре, хәрби кирәк - яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч матдәләр һәм шартлаткыч җайланмалар ирекле тапшырган өчен акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов